# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 11*
*ноябрь*
*2015*
*(I өлеш)*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
СОВЕТЫ РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2015

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 32 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2015

## Эчтәлек

# I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

1135. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .......... 5

1136. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .......... 8

1137. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен 2016 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» *Татарстан Республикасы Законы* .......... 10

1138. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» *Татарстан Республикасы Законы* .......... 11

1139. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* .......... 21

1140. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» *Татарстан Республикасы Законы* .......... 23

1141. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................24

1142. Россия Федерациясе файдасына Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе турында шартнамәгә өстәмә килешү төзүне раслау хакында» *Татарстан Республикасы Законы*..................................................29

1143. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................30

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1135. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) спорт төрләрен үстерү программаларын әзерләүдә бу программаларга Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын, мәктәп спортын, массакүләм спортны, инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар спортын үстерү чараларын кертү өлешендә Федераль закон нигезендә катнашу;»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ – $4^4$ пунктлар өстәргә:

«$4^1$) Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларын һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына спорт резервын әзерләү өчен шартлар тудыру максатларында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү;

$4^2$) массакүләм спортны, югары казанышлар спортын үстерүгә булышу;

$4^{3}$) эшчәнлекләренең төп төре һөнәри спортны үстерү булган физкультура-спорт оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү юлы белән һөнәри спортны үстерүгә булышу;

$4^{4}$) Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларын бөтенроссия, төбәкара һәм төбәк рәсми спорт чараларына әзерләү һәм аларда катнашу чараларын гамәлгә ашыруга булышу, шул исәптән республика спорт федерацияләренә Федераль закон һәм Татарстан Республикасы хокукый актлары нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтү юлы белән дә;»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Федераль законның 22 статьясы нигезендә спорт разрядлары һәм спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү;»;

түбәндәге эчтәлекле $9^{2}$ – $9^{5}$ пунктлар өстәргә:

«$9^{2}$) Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүдә катнашу;

$9^{3}$) спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны методик яктан тәэмин итү;

$9^{4}$) физкультура-спорт оешмалары эшчәнлеген Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләү һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларының төбәкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында катнашуы буенча координацияләү;

$9^{5}$) Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә инновацион һәм эксперименталь эшчәнлекне башкару һәм ирешелгән нәтиҗәләрне гамәлгә кертү өчен шартлар тудыру;»;

б) 2 өлештә:

1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) мәктәп спорты, студентлар спорты үсешенә булышу;»;

2) 12 статьяның $1^{1}$ өлешендә «Волонтерларга» сүзеннән соң «, контролер-эш йөртүчеләргә» сүзләрен өстәргә;

3) 14 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Спорт мастерына кандидат», «беренче спорт разряды» спорт разрядлары һәм «беренче категорияле спорт судьясы» спорт судьясының квалификация категориясе тиешенчә Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәдә һәм Спорт судьялары турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы тарафыннан

биреләләр. «Икенче спорт разряды», «өченче спорт разряды» спорт разрядлары, «икенче категорияле спорт судьясы», «өченче категорияле спорт судьясы» спорт судьяларының квалификация категорияләре тиешенчә Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәдә һәм Спорт судьялары турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан биреләләр. «Яшүсмерләрнең беренче спорт разряды», «яшүсмерләрнең икенче спорт разряды», «яшүсмерләрнең өченче спорт разряды» спорт разрядлары, «яшь спорт судьясы» спорт судьяларының квалификация категориясе тиешенчә Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәдә һәм Спорт судьялары турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә физкультура-спорт оешмалары тарафыннан биреләләр.»;

4) 28 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктка «бүтән» сүзеннән соң «, шул исәптән Федераль законда каралган» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяда:

а) 1 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

б) 3 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

2) 16 статьяның 1 өлешендәге 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) муниципаль район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, муниципаль районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

3) 17 статьяның 1 өлешендәге 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19) шәһәр округы территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр округының рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 89-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1136. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 2 пунктта «башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы белән килештереп, » сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктта «башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы белән килештереп, » сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $13^4$ пункт өстәргә:

«$13^4$) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән Россия Федерациясе Урман кодексының $29^1$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә төзелә торган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләүне исәпләгәндә урманнарны саклау, яклау, торгызу чараларын үткәрүне тәэмин итү чыгымнарын ачыклау өчен кулланыла торган коэффициентны билгеләү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^5$ пункт өстәргә:

«$13^5$) урман фонды җирләре составындагы урман кишәрлекләренә карата урман кишәрлекләренең проект документациясен раслау;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 90-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1137. Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен 2016 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Пенсиягә «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган социаль өстәмә билгеләү максатларында 2016 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен 7526 сум итеп билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 91-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1138. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

1. Җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча дәүләт вәкаләтләре бирелә.

2. Җирлекләрдән кергән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат дигәндә, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясында күрсәтелгән мәгълүмат аңлашыла.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бирелә:

Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган вакыт**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән вакытка бирелә.

5 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару методикасы нигезендә әлеге Законга кушымта буенча башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

6 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булганда, тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә башкарыла.

7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм алырга;

3) муниципаль берәмлекнең уставында каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять белдерергә;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар чыгарырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органына «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда мәгълүмат бирергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләрен үтәргә;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди чараларның исәбен алып барырга һәм алардан тиешлечә файдалануны тәэмин итәргә;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан билгеләнештә файдаланырга;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органына квартал саен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшырырга;

7) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкаруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына кирәкле ярдәм күрсәтергә;

8) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылган очракта файдаланылмаган финанс чараларын, шулай ук матди чараларны кайтарырга.

8 статья. **Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары һәм (яисә) аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү, шул исәптән әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документлар, мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрен карарга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкарырга;

3) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аларга мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә.

9 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзида-рә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге

вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталы тәмамланганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла, моңа дүртенче квартал өчен хисаплылык керми, ул хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

10 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан — җирле үзидарә органнарының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырулары өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген урыннарга чыгып тикшерү;

в) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча законнар таләпләрен бозуларны бетерү буенча мәҗбүри үтәлергә тиешле язма күрсәтмәләр бирү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан — дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген урыннарга чыгып тикшерү;

3) Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге

вәкаләтле органы тарафыннан – җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган дәүләт мөлкәтен саклау һәм тиешенчә куллану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген урыннарга чыгып тикшерү;

в) бозуларны бетерү һәм аларны булдырмау буенча кирәкле чаралар күрү.

11 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы законы белән башкарыла:

1) җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм (яисә) аларның вазыйфаи затлары әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп үзгәртелгәндә.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди чараларны кайтаруны таләп итә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланганнан соң 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрәләр.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көненнән алып ун көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре хакында мондый күрсәтмәне җибәргән органга кичекмәстән язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы үз компетенцияләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдимнәр һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертәләр.

12 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 92-ТРЗ

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

## Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару методикасы

Әлеге Методика муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

I-муниципаль районына субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = O_i : V \times R \times K_i,$$

монда:

$S_i$ – i-муниципаль районы бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенция күләме;

$O_i$ – i-муниципаль районында хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алып (бер елга исәпләгәндә), дәүләт вәкаләтләрен башкаручы белгечкә тулаем акчалата түләүне бирү чыгымнары;

V – план елына производство календаре белән билгеләнгән эш вакыты, сәгать;

R – бер җирлектән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле

мәгълүматны алуга һәм эшкәртүгә вакыт нормасы, бер елга сәгать (1 сәгать күләмендә билгеләнә);

$K_i$ – i-муниципаль районындагы җирлекләр саны.

Дәүләт вәкаләтләрен башкаручы белгечкә тулаем акчалата түләүне бирү чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_i = (Z_i + N_i) \times 12,$$

монда:

$Z_i$ – i-муниципаль районын хезмәт өчен түләү төркеменә кертүне исәпкә алып, i-муниципаль районы башкарма комитетының (башкарма комитеты аппаратының) I категория белгече вазыйфасы дәрәҗәсендә билгеләнә торган айлык акчалата түләү күләме;

$N_i$ – хисап чорына хезмәт хакына карата түләүләр.

Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләре гамәлгә ашырылганда хезмәт хакына карата түләүләр чыгымнары исәбенә эш бирүче тарафыннан федераль законнар нигезендә федераль бюджетка, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бюджетына (производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәрен кертеп), Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды һәм территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына күчерелә торган хезмәт хакына карата түләүләр керә.

Хезмәт хакына карата түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$N_i = Zj \times F ,$$

монда:

F – хезмәт хакына карата түләүләрнең ставкасы.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1139. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда «һәм әлеге Закон» сүзләрен «, әлеге Закон, шулай ук Татарстан Республикасының алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актлары» сүзләрен өстәргә;

2) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлегенең матди һәм социаль гарантияләре**

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлегенең матди һәм социаль гарантияләре судьялар статусы турындагы федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының гомуми акчалата хезмәт хакына судьялар статусы турындагы федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә судьяның аңа бирелгән квалификация классына туры килә торган вазыйфаи оклады, айлык окладык, өстәмә түләүләр, өстәлмәләр һәм башка төр түләүләр керә.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасарының һәм Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вазыйфаи окладлары күләмнәре тиешенчә Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе урынбасарының һәм Татарстан Республикасы Югары суды судьяларының вазыйфаи окладлары күләмнәренә тигез.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының гомуми акчалата хезмәт хакы судьялар статусы турындагы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.»;

2) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 93-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1140. Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 18 статьясындагы 2 пунктының, $53^1$ статьясындагы 2 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) гамәлдә булуын 2016 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 19 ноябре
№ 94-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1141. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «10 | Автомобиль транспортында йөкләр ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 270 | 3 000 | 600 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «10 | Автомобиль транспортында йөкләр ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 600 | 3 000 | 600 | 5 000»; |

2)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.1 | Такси эшчәнлеге | транспорт чарасы | 250 | 3 000 | 500 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.1 | Такси эшчәнлеге | транспорт чарасы | 500 | 3 000 | 500 | 5 000»; |

3)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.2 | Пассажирлар йөртү буенча, такси эшчәнлегеннән тыш, автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 000 | 3 000 | 1 800 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.2 | Пассажирлар йөртү буенча, такси эшчәнлегеннән тыш, автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 800 | 3 000 | 1 800 | 5 000»; |

4)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «33 | Су транспортында йөк ташу хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 250 | 3 000 | 1 000 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «33 | Су транспортында йөк ташу хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 000 | 3 000 | 1 000 | 5 000»; |

5)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 3 450 | 10 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе | | | | | » |

һәм аннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46.1 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе (таратыла торган ваклап сату сәүдәсеннән тыш) | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 3 450 | 10 000 |
| 46.2 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе (таратыла торган ваклап сату сәүдәсе өлешендә) | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 2 500 | 10 000»; |

6)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «47 | Җәмәгать туклануы оешмасының һәр объекты буенча кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы 50 квадрат метрдан артыграк булмаган мәйданлы җәмәгать туклануы оешмасы объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | җәмәгать туклануы оешмасы объекты | 1 200 | 10 000 | 1 950 | 10 000» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «48 | Кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы булмаган җәмәгать туклануы оешмасы объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы буенча хезмәт күрсәтүләр | җәмәгать туклануы оешмасы объекты | 1 000 | 1 000 | 1 950 | 5 000 |
| 49 | Терлек сую, транспортировкалау, куып алып бару, көтү буенча хезмәт күрсәтүләр | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 50 | Күн һәм күн әйберләр җитештерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 51 | Ашарга ярый торган урман ресурсларын, агач булмаган урман ресурсларын һәм дару үләннәрен җыю һәм әзерләү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 52 | Җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне киптерү, эшкәртү һәм консервлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 53 | Сөт продукциясе җитештерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 54 | Җиләк-җимеш үсентесе материалларын җитештерү, яшелчә культуралары үсентеләре һәм үлән орлыклары үстерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 55 | Икмәк һәм камыр ашы кондитерлык әйберләре җитештерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 56 | Товар һәм спорт балыкчылыгы һәм балык үрчетү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 57 | Урманчылык тармагы һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 58 | Язма һәм телдән тәрҗемә эшчәнлеге | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 59 | Өлкәннәрне һәм инвалидларны карау эшчәнлеге | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 60 | Калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү, шулай ук икенчел чималны эшкәртү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 61 | Һәйкәлләр өчен таш кисү, эшкәртү һәм бизәү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 62 | ЭВМ һәм белешмәләр базасы (исәпләү техникасының программа чаралары һәм мәгълүмат продуктлары) өчен программалар эшләү буенча хезмәт күрсәтүләр (эшләр башкару), аларны яраклаштыру һәм модификацияләү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 63 | Компьютерлар һәм коммуникация җайланмаларын ремонтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000». |

**2 статья**

Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 19 ноябре
№ 95-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1142. Россия Федерациясе файдасына Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе турында шартнамәгә өстәмә килешү төзүне раслау хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Россия Федерациясе файдасына Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе турында 2005 елның 7 декабрендәге 01-01-06/04-159 номерлы шартнамәгә «2015 елга һәм 2016, 2017 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2014 елның 1 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 10 өлешендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 14 сентябрендәге 1801-р номерлы күрсәтмәсендә каралган шартларда өстәмә килешү төзүне расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 19 ноябре
№ 96-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1143. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

1. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 160 598 427,5 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 166 431 376,9 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 5 832 949,4 мең сум итеп.

2. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2017 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 103 558 807,4 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 9 907 800,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң чик күләмен 118 172 484,4 мең сум күләмендә расларга.

3. 2016 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. 2016 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бюджет кредитлары җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын башкару хокукы бирергә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60[1] статьясындагы 2 пункты нигезендә 2016 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

2016 елга Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә җирле бюджетларга күчерелергә тиешле дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәрен әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләре, 2015 ел нәтиҗәләре буенча чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча акционер җәмгыятьләрнең идарә органнары (директорлар советы, күзәтчелек советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны 2016 елның 1 сентябренә кадәр (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табышның кимендә 30 проценты күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2016 елда Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2015 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка

мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше 2016 елның 1 июленә кадәр әлеге табышның 30 проценты күләмендә кертелә дип билгеләргә.

**7 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

**8 статья**

1. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. 2016 елга бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

4. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 19 485 734,2 мең сум күләмендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пунктына таянып, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә 2016 елда үзгәрешләр кертү әлеге статьяда расланган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган түбәндәгеләрне бүлүгә нигезләнә дип билгеләргә:

1) бюджетлар чыгымнары классификациясендә «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегенең «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе буенча:

оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымын түләүгә – 2 791 651,2 мең сум күләмендә;

дәүләт (муниципаль) учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чараларга – 2 726 560,9 мең сум күләмендә;

2) бюджетлар чыгымнары классификациясендә «Торак-коммуналь хуҗалык» бүлегенең «Торак хуҗалыгы» бүлекчәсе буенча социаль-мәдәни өлкә объектларын файдалануга кабул итүгә һәм гамәлгә кертүгә – 1 500 000,0 мең сум күләмендә.

**9 статья**

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр, үз керемнәре һәм Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән финанслана торган субвенцияләр, бюджетара субсидияләр, әлеге Законда каралган башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**10 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2016 елда җирлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен хисап финанс елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2016 елда 3 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

**11 статья**

1. 2016 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 40 395,6 мең сум итеп расларга

һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 40 395,6 мең сум күләмендә бирергә.

2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр исәпләп чыгарганда һәм муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр исәпләп чыгарганда кулланыла торган шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп), авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру буенча финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечен 2016 елга түбәндәгечә билгеләргә:

шәһәр җирлекләре буенча (шәһәр округларын кертеп) – бер кешегә исәпләгәндә 1 175,9 сум итеп;

авыл җирлекләре буенча – бер кешегә исәпләгәндә 202,8 сум итеп.

**12 статья**

1. 2016 елга муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен 10 085 538,3 мең сум күләмендә расларга.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дотацияләрне 2016 елда 8 891 641,2 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары белән алмаштырырга.

3. 2016 елга муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан суммаларның шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 12 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә кулланыла торган муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие күрсәткечен 2016 елга 2,109 итеп билгеләргә.

**13 статья**

1. 2016 елга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлүне әлеге Законга 13 – 34 нче кушымталар нигезендә расларга.

